**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Автоном Совет Социалистик Республикасы оешуга 100 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Автоном Совет Социалистик Республикасы оешуга 100 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты эшчәнлеген камилләштерү максатларында, шулай ук кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Автоном Совет Социалистик Республикасы оешуга 100 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты төзү турында» 2016 елның 11 гыйнварындагы ПУ-1 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 16 июнендәге ПУ-504 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы һәм 2018 елның 6 июлендәге ПУ-473 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Автоном Совет Социалистик Республикасы оешуга 100 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) оештыру комитеты составыннан Т.Ю. Васильеваны, Э.Э. Искәндәровны чыгарырга;

б) оештыру комитеты составына кертергә:

Кыямов Руфат Рифгать улын – «Татарстан Республикасы Студентлар лигасы» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы президентын (килешү буенча);

Кузьмичева Елена Ивановнаны – Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе рәисен (килешү буенча);

Миргалимов Хафиз Гаяз улын – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты рәисе урынбасары, «Россия Федерациясенең Коммунистлар партиясе» сәяси партиясенең Татарстан төбәк бүлекчәсе Комитеты беренче секретарен (килешү буенча);

Нигъмәтуллина Гөлшат Рәдиф кызын – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе башлыгын.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 19 апрель
№ ПУ-241